КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 19 август г.Казань № 866

Татарстан Республикасының экологик туристлык өлкәсендә ял һәм рекреация объектлары реестрын төзү һәм алып бару тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасында экологик туристлык өлкәсен үстерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасының экологик туристлык өлкәсендә ял һәм рекреация объектлары реестрын төзү һәм алып бару тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетын Татарстан Республикасының экологик туристлык өлкәсендә ял һәм рекреация объектлары реестрын төзүгә һәм алып баруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы итеп билгеләргә.

3. 3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин